КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 19 июль г.Казань № 603

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасында 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алу буенча комиссия төзү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану турында» 2019 ел, 15 август, 682 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 18 октябрь, 935 нче; 2019 ел, 11 декабрь, 1137 нче; 2020 ел, 7 апрель, 261 нче; 2020 ел, 11 декабрь, 1120 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алу буенча комиссия составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Комиссия составыннан О.В.Пелевинны чыгарырга;

Комиссия составына Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары – Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының Социаль-икътисадый мониторинг департаменты башлыгы Роман Дамир улы Әмирхановны кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны оештыру турында» 2020 ел, 19 август, 709 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 11 декабрь, 1120 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. 2021 елның 1 октябреннән 31 октябренә кадәр Татарстан Республикасы территориясендә Бөтенроссия халык санын алуны үткәрергә.»;

8 пунктның икенче абзацында «2020 елда һәм 2021 елның беренче ярты-еллыгында» сүзләрен «2021 елның икенче яртыеллыгында» сүзләренә алмаш-тырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин